Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл жирлегенец Көшкәтбаш торак пунктында ХАЛЫК ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

**2022 елнын 06 ноябре** **№2**

Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы. "Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында" 2003 елнын 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнын 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, "Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында" 23.11 Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл жирлеге Уставы һәм «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар жыеныи әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» гы 2022 елның 24 октябрендәге 6 номерлы карар нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлегендә гражданнар җыенын үткәрү турында Көшкәтбаш торак пунктында халык жыены Карар кабул итте:

1. 2023 елда территориядә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 800 сум күләмендә үзсалым кертергә. Югары Субаш авыл жирлеге Көшкәтбаш торак пунктында 1 төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәкләрдән, үз-үзенә хезмәт күрсәтә алмаган гражданнардан, армия сафларында хезмәт итүгә сәләтсез гражданнардан, ялгыз аналардан, гаиләдән тыш, социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаган балалары булган, яшәү урыны буенча теркәлгән, әмма яшәмәүче, Бөек Ватан сугышының тол хатыннарыннан тыш, мобилизацион гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары өчен үзара салым суммасының 90% күләмендә ташлама билгеләнгән; көндезге уку формасы буенча укучы студентларга, алар өчен үзара салым суммасының 50% күләмендә ташлама билгеләнгән. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә жибәрергә:
- Көшкәтбаш авылында су башнясы сатып алу, китерү;
- Көшкәтбаш авылына су башнясы бушатканда автокран хезмәте;
- Көшкәтбаш авылының су белән тәэмин итү челтәренә су башнясын монтажлау һәм тоташтыру;
- Көшкәтбаш авылындагы яр буе урамына таш өстәп юл профилен төзәтү;
- Көшкәтбаш авылына үлән чабу.

2. Халык жыены нәтиҗәләрен Югары Субаш авыл жирлеге Советының мәгълүмәти стендларында урнаштырырга, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълумат рәсми порталында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Балтач муниципаль районы сайтында бастыру юлы бел эн халыкка житкерергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар жыенында рәислек итүче
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе

А.А.ХӨСНЕТДИНОВ